МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.05.2018 г.Казань № 351

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 13 июнендә теркәлде, № 4736

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.05.2018 № 351 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 № 533, 06.06.2016 № 316, 28.11.2016 № 668, 29.03.2017 № 194, 08.06.2017 № 349, 22.12.2017 № 895 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.4 пунктта:

1.4.1 һәм 1.4.2 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашу урыны, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат әлеге Регламентка белешмәлек кушымтада күрсәтелде.

Үзәк бүлегенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәк бүлегенең эш сәгатьләрендә, алар «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Үзәк) эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә.

Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаларны кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәкнең эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

1.4.2. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Үзәк бүлекләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында – http://mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә)(mtsz@tatar.ru).»;

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.5 пунктның кырык тугызынчы абзацында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре» сүзләрен «Интернет» челтәре» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:

бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

эшсезлек буенча пособие, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтәнчә түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорына гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашуы чорында түләнә торган түләүләр, шулай ук вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарга түләүләр турында белешмәләр (халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте органнарында);

түбәндәгеләрнең күләмнәре турында: пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә ай саен түләнә торган матди тәэминатларның (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында (Россия Федерациясе Пенсия фонды);

пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында (Россия ЭЭМ);

хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында белешмәләр (Россия Оборона министрлыгы);

социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында);

йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль

иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, социаль яклау органнары түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында белешмәләр, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында);

алучының гаилә составы турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала караган өчен акча алуы турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

уналты яшьтән олырак булган баланың (балаларның) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмәләр (гомуми белем бирү оешмасыннан).

Гариза бирүче Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә гариза бирүченең паспортының чын булуын раслау турында белешмәләр алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Аталган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Мөрәҗәгать итүчедән югарыда саналган, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында булган оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш»;

2.15 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.»;

3 бүлекнең 3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта, ГХАТ органнарыннан;

эшсезлек буенча пособие түләүләре, матди ярдәм һәм эшсез гражданнарга башка төрле түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы нигезендә һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм түләүләре турында – халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте органыннан:

түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә ай саен түләнә торган матди тәэминатларның – Россия Федерациясе Пенсия фонды органыннан;

социаль яклау органнарыннан социаль яклау органнары тарафыннан йөклелек һәм бала тудыру буенча түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр;

социаль яклау органнарыннан йөклелекнең башлангыч срокларында медицина учреждениеләренә исәпкә куелган хатын-кызларга социаль яклау органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр;

социаль яклау органнарыннан социаль яклау органнары тарафыннан бала караган өчен түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында белешмәләр;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарыннан;

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, социаль яклау органнары түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында – социаль яклау органнарыннан;

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә

торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында – социаль яклау органнарыннан;

дәүләт хезмәте алучының гаилә составы турында – вәкаләтле оешмалардан.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр алу.

3.4.2. Балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта, – ГХАТ органнарына;

Россия Федерациясе Пенсия фондына хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр;

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) баланы асрауга акча алуы турында, – җирле үзидарә органнарына;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында, – җирле үзидарә органнарына;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында белешмәләр, – җирле үзидарә органнарына;

дәүләт хезмәте алучының гаилә составы турында (йорт кенәгәсеннән өземтә) – вәкаләтле органнарга;

хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында белешмәләр – Россия Оборона министрлыгына;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса, – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтле булмау буенча пособие, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие, шулай ук медицина учреждениеләрендә йөклелекнең башлангыч срокларында исәпкә алынган хатын-кызларга бер бирелә торган пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

бала караган өчен айлык пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында – Россия Федерациясе Пенсия фондына;

Россия Эчке эшләр министрлыгына – пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;

мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуын раслау турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, әгәр гариза Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән булса;

уналты яшьтән олырак булган баланың (балаларның) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмәләр, – гомуми белем бирү оешмасына.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамә.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Үзәк яисә Идарә (бүлек) җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк яисә Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшереп торучы урынбасары яисә министр исеменә тапшырыла.

Министр урынбасарының (министрның) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (учреждение хезмәткәре) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәткәренең (учреждение белгеченең), дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение) җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлыкның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлык вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлеге
________________________________________
________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ____

«__» __________ 20__ ел.

Мин,
______________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча яшим:
___________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)
түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:
___________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләрендә эш итүен раслаучы документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
Снилс (алучыныкы) __________
Түбәндәгене билгеләүне сорыйм ___________________________________________,
(дәүләт хезмәте алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
___________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучының почта адресы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
___________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучының шәхесен таныклаучы документ реквизитлары)
___________________________________________________________________________

| № | Түләүнең аталышы | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|---|
| 1 | Балага ай саен түләнә торган пособие | |

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Түләү алучының гаилә составы:

| № | Ф.И.А. (туу датасы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары | Кирәклесен билгеләргә <*> |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |

<*> хезмәтләр билгеләнә торган балалар билгеләнә

Раслыйм: гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында тормавы, шулай ук ______________________________________ карата
(дәүләт хезмәте алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-аналык хокукында чикләнмәгән.

_________ ___________________________
(имза, тулы имза)

___________________________________________________________________________________
(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)

Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:
счет реквизитлары___________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә банкта яисә башка төрле кредит учреждениесендә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)
почта бүлеге реквизитлары ___________________________________________________
(дәүләт хезмәтен алучының яисә аның законлы вәкиленең почта реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең төгәл булуы, шулай ук аларны үз эченә алган документларның хаклыгы өчен җаваплы булам _________________________________
(гариза бирүченең имзасы)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әлеге Гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларымны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган тәртиптә, саклауга һәм өченче затларга мәгълүмат белән алмашу системасында тапшыруга ризалыгымны бирәм___________________
(гариза бирүченең имзасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза.

язмача
смс-хәбәр белән _______________________
(телефон номеры)
электрон почта буенча ____________________
(электрон почта адресы)
Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша _____________________
(гариза бирүченең имзасы)

Эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан минем файдага түләнгән түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр суммасы турында Россия Федерациясе Пенсия фондында социаль ярдәм чаралары билгеләү буенча мөрәҗәгать итү аеннан алда килүче соңгы 6 ай һәм 12 ай өчен булган белешмәләр нигезендә балага ай саен түләнә торган пособие билгеләүгә, шул исәптән яңа чорга автомат рәвештә билгеләүгә, риза. ________________________________________
(гариза бирүченең имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде

__________ ____________ __________________________
(дата, белгеч имзасы, тулы имзасы)

---

Өзү линиясе

Язу-белдерүнамә

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №_____________

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте

___________ __________ _________________________ ______________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Читләр каравына (ярдәменә, күзәтүенә) даими мохтаҗ булган инвалид балаларга 18 яшенә җиткәнче өстәмә ай саен түләнә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 490 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 23.03.2017 № 171, 08.06.2017 № 349 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Читләр каравына (ярдәменә, күзәтүенә) даими мохтаҗ булган инвалид балаларга 18 яшенә җиткәнче өстәмә ай саен түләнә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.4 пунктта:

1.4.1 һәм 1.4.2 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашу урыны, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат әлеге Регламентка белешмәлек кушымтада күрсәтелде.

Үзәк бүлегенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәк бүлегенең эш сәгатьләрендә, алар «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Үзәк) эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә.

Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаларны кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәкнең эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

1.4.2. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Үзәк бүлекләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында – http://mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә)(mtsz@tatar.ru).»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Аз керемле дип тану һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен керемнәрне исәпкә алу һәм гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләү тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 14, 1257 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – РФ Президентының 601 номерлы Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәрнең төрләре исемлеге турында» 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 512 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 34, 3374 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 елның 07 мартындагы 188 номерлы карары белән расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – 188 номерлы нигезләмә)(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 24, 0743 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 елның 07 мартындагы 188 номерлы карарының 1 п.»;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымтада бирелгән форма нигезендә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза (1 нче кушымта).

2. Инвалид баланың даими рәвештә кеше тәрбиясенә (ярдәмгә, күзәтүгә) мохтаҗ булуы турында билгеләнгән формалы, «Татарстан Республикасы буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе тарафыннан бирелгән белешмә яисә тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча хосусый программаның инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтү сәләтендә чикләнүнең өченче дәрәҗәсе турында тамга куелган күчермәсе.

3. Гариза биргән айдан алда килүче 3 айда гаиләнең һәр әгъзасы тарафыннан акчалата һәм натураль формада алынган керемнәр турында документлар, шул исәптән:

а) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барча түләүләр турында»;

б) хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача хезмәт хакы турында;

в) дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация турында;

г) эштән куылганда түләнә торган ял пособиесе, отставкага киткәндә компенсация, оешма ликвидацияләнүгә, хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән куылганда хезмәткә урнашу чорына саклана торган хезмәт хакы турында;

д) барлык дәрәҗә бюджетлардан, дәүләтнең бюджетка карамаган фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр, андыйларга түбәндәгеләр керә:

пенсияләр, компенсация түләүләре (эшләми торган хезмәткә сәләтле, хезмәткә сәләтсез булган гражданнарны караучы затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм ай саен түләнә торган пенсионерларның матди тәэминаты (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган түләүләрдән гайре);

отставкага киткән судьяларны ай саен гомер буе тәэмин итү;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучыюгары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр сәламәтлек саклау учреждениесенең бәяләмәсе буенча аларның балалары 18 яшенә җиткәнче читләрнең каравына мохтаҗ булса, ирнең хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда ай саен түләнә торган пособие;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эш белән тәэмин итү мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына ай саен түләнә торган компенсация түләүләре;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре;

әлеге пунктчада күрсәтелгән барлык төр социаль түләүләргә өстәмә һәм кушып түләүләр (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән бүтән социаль түләүләр (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);

е) хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм 3 яшенә җиткәнче бала карау ялында булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);

ж) милекчелек хокукында гаиләнеке (андагы аерым әгъзаларныкы) яисә ялгыз яшәүче гражданинныкы булган мөлкәттән алынган керемнәр, андыйларга түбәндәгеләр керә:

күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гараждарны), транспорт һәм бүтән механика чараларын, продуктларны эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (наемга) бирүдән алынган керемнәр;

шәхси ярдәмче хуҗалык уңышын һәм продукциясен (күп еллык утыртмалар, яшелчәчелек продукциясе, продукция һәм демонстрация хайваннары, кошлар, кыйммәтле мехлы җәнлекләр, бал кортлары, балыклар) сатудан алынган керемнәр;

з) гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданинның башка керемнәре турында, аларга түбәндәгеләр керә:

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарның хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими холыкка ия булган өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә азык-төлек тәэминаты;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнардан эштән киткәндә бер мәртәбә бирелә торган пособие;

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләргә түләү;

эш бирүчеләр тарафыннан үзләренең, шул исәптән инвалидлык яисә яше җитүгә бәйле рәвештә пенсиягә чыгу сәбәпле элеккеге, эштән киткән хезмәткәрләренә матди ярдәм;

Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турында законнары нигезендә алына торган авторлык бүләкләүләре, шул исәптән мирас итеп алуның авторлык шартнамәләре буенча;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьянлык (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр;

акцияләр буенча керемнәр һәм оешма мөлкәте белән идарә итүдә катнашудан алынган башка керемнәр;

гаилә әгъзалары тарафыннан алына торган алиментлар;

банк кертемнәре буенча процентлар;

мирас итеп алына һәм бүләк ителә торган акча чаралары;

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән ташламалардан һәм социаль гарантияләрдән гаилә әгъзалары алган акчалата эквивалентлар.

4. Алучының гаилә әгъзаларыннан аларның персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы булуын раслаучы документ(лар) (ирекле формада).

5. Әгәр айлык акчалата түләү билгеләү буенча гариза вәкаләтле зат тарафыннан тапшырылса, вәкаләтле затлар өчен ышанычнамә.

Гаризаны тапшырганда мөрәҗәгать итүче паспортын (аны алмаштыра торган документны) күрсәтә һәм кредит оешмаларында ачтырылган шәхси счет реквизитларын тапшыра.

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган документларның күчермәләре төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан таныклана.

Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәтен алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне раслаучы документлар алына:

бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

инвалид балага опека (попечительлек) билгеләнүе, инвалид баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру, инвалид баланың тулысынча дәүләт тәэминатында торуы турында (җирле үзидарә органнарында);

дәүләт хезмәте алучының ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителүе яисә ата-аналык хокукында чикләнүе турында – җирле үзидарә органнарына;

дәүләт хезмәте алучының гаилә составы турында (вәкаләтле оешмалардан);

хезмәткә сәләтсез гражданнарны тәрбияләүче затларга билгеләнгән компенсация түләвенең законлы вәкил тарафыннан алынуын раслау (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

эшсезлек буенча барлык төр пособие түләүләре (түләүләрнең булмавы) һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан);

түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: пенсияләр, компенсация түләүләре (эшкә сәләтсез гражданнарны тәрбия кылучы, эшкә сәләтле эшләүмәүче затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионерларны ай саен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырылучы материаль тәэмин итү буенча түләүләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

Россия Эчке эшләр министрлыгына – пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;

хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында белешмәләр (Россия Оборона министрлыгы);

социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондына);

йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

социаль яклау органнары тарафыннан балага түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында (социаль яклау органнарында);

әлеге пунктчада күрсәтелгән, социаль яклау органнары түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында).

Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, үз ихтыяры белән тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүчедән югарыда саналган, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында булган оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш»;

9.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

затның шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән документлар белән мөрәҗәгать итүе;

дөрес (төгәл) булмаган мәгълүматларны үз эченә алучы документлар тапшырылуы;

дәүләт хезмәте алучының тулысынча дәүләт тәэминатында торуы;

дәүләт хезмәтен алучыга карата ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителгән яисә суд карары нигезендә ата-аналык хокукында чикләнгән затның мөрәҗәгать итүе;

дәүләт хезмәте алучының инвалид баланы тәрбия кылучы эшләми торган хезмәткә сәләтле затка компенсация түләвенең рәсмиләштерелмәгән булуы;

2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза һәм документлар килгән көнне.

Гариза белән кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә»;

2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү озынлыгы 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.»;

2.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

Документларны (документларның күчермәләрен) электрон документлар формасында тапшырган очракта, әгәр алар 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләр нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) булса, бер бирелә торган түләүне билгеләү мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә төп нөсхәләрне яисә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрен кәгазьдә тапшырганнан соң гамәлгә ашырыла»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

айлык акчалата түләү билгеләү буенча документлар җыелмасын теркәп, гаризаны кабул итү һәм теркәү, яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша Үзәк бүлегенә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк белгече шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать иткән ысулы нинди булуга карап, мөрәҗәгать итүчене, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен зарури булган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияли һәм мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче айлык акчалата түләү билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлегенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документларны (документларның күчермәләрен) теркәп тапшыра.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән тыш) почтадан, җибәрелү фактын һәм датасын раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән, җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләр нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

3.3.2. Үзәк бүлеге хезмәткәре дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.8 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаганда, Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап язу тапшыра, гариза почтадан һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгәндә, – гаризаны теркәү датасы һәм беркетелгән керү номеры турында хәбәрләмә җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк бүлеге белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм докуметлар Үзәк бүлегенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлегенең эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы көндә. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, язунамә яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, ГХАТ органнарыннан;

эшсезлек буенча барлык төр пособие түләүләре һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан;

түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: пенсияләр, компенсация түләүләре (эшкә сәләтсез гражданнарны тәрбия кылучы, эшкә сәләтле эшләүмәүче затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионарларны ай саен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә

ашырылучы материаль тәэмин итү буенча түләүләр турында Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

социаль яклау органнарыннан социаль яклау органнары тарафыннан йөклелек һәм бала тудыру буенча түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр;

социаль яклау органнарыннан йөклелекнең башлангыч срокларында медицина учреждениеләренә исәпкә куелган хатын-кызларга социаль яклау органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр;

социаль яклау органнарыннан социаль яклау органнары тарафыннан бала караган өчен түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында белешмәләр;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнары;

социаль яклау органнары тарафыннан балага түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында – социаль яклау органнарына;

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, социаль яклау органнары түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында – социаль яклау органнарында;

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында – социаль яклау органнарында;

дәүләт хезмәте алучының гаилә составы турында – вәкаләтле оешмалардан.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр алу.

3.4.2. Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында һәм теркәү акты Татарстан Республикасыннан читтә алынган очракта, балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында – ГХАТ органнарына;

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фондында;

инвалид балага опека (попечительлек) билгеләнүе, инвалид баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру, инвалид баланың тулысынча дәүләт тәэминатында торуы турында – җирле үзидарә органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарыннан;

дәүләт хезмәте алучының ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителүе яисә ата-аналык хокукында чикләнүе турында – җирле үзидарә органнарына;

хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында белешмәләр – Россия Оборона министрлыгына;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе

бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса, – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтле булмау буенча пособие, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие, шулай ук медицина учреждениеләрендә йөклелекнең башлангыч срокларында исәпкә алынган хатын-кызларга бер бирелә торган пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

бала караган өчен айлык пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

Россия Эчке эшләр министрлыгына – пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;

хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы затларга билгеләнгән компенсация түләвенең законлы вәкил тарафыннан алынуын раслаучы белешмәләр, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Пенсия фонды органнарына;

дәүләт хезмәте алучының гаилә составы турында (йорт кенәгәсеннән өземтә) – вәкаләтле органнарга;

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамә.

3.5. Айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү

3.5.1. Үзәк бүлеге белгече әлеге Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларында күрсәтелгән белешмәләр һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектын рәсмиләштерә;

айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектын имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гарызнамәләргә җаваплар килгән көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көнненән дә соңга калмыйча.

Процедураларның нәтиҗәсе: айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юлланган карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе документларны караганнан соң айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектына имза сала һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе имзалаган айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар хакында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (хат белән, смс-хәбәр белән, электрон почта ярдәмендә) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар Үзәк бүлеге белгеченә җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү күпфункцияле үзәктә һәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

3.8. Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

Айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарны үзгәртеп рәсмиләштерү айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарда җибәрелгән техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) юкка чыгаруга бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарны үзгәртеп рәсмиләштерү техник хатасы булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган документ (мондый документ бирелү очрагында) белән теркәлгән гариза (гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка 5 нче кушымтада китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хата төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза салу өчен юлланган айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проекты.

3.8.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарга кул куя һәм аны Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе имзалаган айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.

3.8.3. Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән ысул белән (язмача, смс-хәбәр итеп, электрон почтадан) мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар хакында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар Үзәк бүлеге белгеченә җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү.»;

4 бүлектә:

4.1 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.1. Үзәк бүлегендәге белгечләрнең Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләрен үтәвен һәм башкаруын көндәлек тикшереп тору Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәүгә һәм башкаруга карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибе һәм рәвешләре Үзәк директоры тарафыннан билгеләнә.»;

4.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору Министрлык аппараты бүлегенең һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) (алга таба – Идарә (бүлек)) әлеге тикшереп торуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Үзәк яисә Идарә (бүлек) җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк яисә Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшереп торучы урынбасары яисә министр исеменә тапшырыла.

Министр урынбасарының (министрның) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (учреждение хезмәткәре) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәткәренең (учреждение хезмәткәренең), дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение) җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлыкның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлык вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Читләр каравына (ярдәменә, күзәтүенә) даими мохтаҗ булган инвалид балаларга 18 яшенә җиткәнче өстәмә ай саен түләнә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлеге ______________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ____

«__» __________ 20__ ел.

Мин,
______________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча яшим:
______________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)
түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:
______________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләрендә эш итүен раслаучы документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
Снилс (алучыныкы) ___________
Түбәндәгене билгеләүне сорыйм _____________________________________________,
(дәүләт хезмәте алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
______________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының почта адресы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының шәхесен таныклаучы документ реквизитлары)

________________________________________________________________________

Читләр каравына (ярдәменә, күзәтүенә) даими рәвештә мохтаҗ булган инвалид балаларга 18 яшенә җиткәнче өстәмә айлык акчалата түләү балага ____________________________________________________________

(баланың Ф.И.А.)

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Түләү алучының гаилә составы:

| № | Ф.И.А. (туу датасы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |

Раслыйм: гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында тормавы, шулай ук ________________________________________ карата

(дәүләт хезмәте алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-аналык хокукында чикләнмәгән.

__________ _____________________________

(имза, тулы имза)

________________________________________________________________________

(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)

Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:

счет реквизитлары______________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә банкта яисә башка төрле кредит учреждениесендә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге реквизитлары ________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының яисә аның законлы вәкиленең почта бүлеге реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең төгәл булуы, шулай ук аларны үз эченә алган документларның хаклыгы өчен җаваплы булам ________________________________

(гариза бирүченең имзасы)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әлеге Гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларымны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган тәртиптә, саклауга һәм өченче затларга мәгълүмат белән алмашу системасында тапшыруга ризалыгымны бирәм

____________________

(гариза бирүченең имзасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза: _____________________________________

(язмача, смс-хәбәр белән, электрон почта буенча)

Мөрәҗәгать итүче:

_____________________________________________ _________________ _________

(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А.) (имзасы) (дата)

Гариза һәм документлар кабул ителде

_________ __________ _______________________

(дата, белгеч имзасы, тулы имзасы)

---

Өзү линиясе

Язу-белдерүнамә

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №____________

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте

__________ _________ _______________________ _____________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентның 5 нче кушымтасын көчен югалткан дип танырга;

Регламентның 7 нче кушымтасын тиешенчә 5 нче кушымта дип исәпләргә.